**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ЛАИШЕВСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ МАЛОЕЛГИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

422619, с. Малая Елга
ул.Советская, д.58
тел: 8-(84378) -3-25-16
факс: 8-(84378) -3-25-16
e-mail:Melg.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КЕЧЕ ЕЛГА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**

422619, Кече Елга авылы,
Совет урамы, 58нче йорт,
тел: 8-(84378) -3-25-16
факс: 8-(84378) -3-25-16
e-mail:Melg.La@tatar.ru

**2023 елның «26» апреле** **7 номер**

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Кече Елга авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2021 елның 20 октябрендәге 33 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Лаеш муниципаль районы Кече Елга авыл җирлеге Советы «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән карар **кабул итте**:

1) Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Кече Елга авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2021 елның 20 октябрендәге 33 номерлы карарына, кушымта нигезендә, үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2) Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

3) Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы Кече Елга
авыл җирлеге Советы рәисе** **Р.З.Хисамов**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы
Кече Елга авыл җирлеге Советының 2023 елның 26 апреле
7 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Кече Елга авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2021 елның 20 октябрендәге 33 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү

1) **2.2 пунктындагы «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

"Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында»2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы башлыгы (Рәисе) тарафыннан вәкаләтләнгән махсуслаштырылган оешмалар милкендәге җир кишәрлекләренә карата 0,001%;".

».